| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.11.2016 Казан ш. № 7-17/т

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр чите тимер юл транспортында «Содружество» ачык акционерлык җәмгыяте пассажирларны йөрткән өчен икътисади нигезләнгән тарифлар дәрәҗәсен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы федераль законга ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1995 елның 7 мартындагы «Бәяләрне (тарифлар) дәүләт көйләвен җайга салу чаралары турында» 239нчы карары һәм 2009 елның 5 августындагы «Тимер юлда йөртү өлкәсендә табигый монополийләр субъектлары эшендә тарифлар, җыемнар һәм түләүләрне дәүләт көйләве турында» 643нче карары белән, тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2010 елның 28 сентябрендәге «Россия Федерациясе субъектларында шәһәр чите тимер юл транспортында пассажирлар йөртү өлкәсендә табигый монополийләр субъектлары хезмәтләре өчен бәяләр (тарифлар) ясаганда исәпкә алынган икътисади нигезләнгән исәпләүләр методикасын раслау турында» 235-т/1нче һәм 2011 елның 19 августындагы «Тимер юл транспортында пассажирлар йөртү өлкәсендә табигый монополийлар субъектлары эшендә (хезмәтләр) тарифлар, җыемнар һәм түләүләрне билгеләү буенча мәсьәләләрне карау тәртибен һәм шулай ук билгеләү (үзгәртү) өчен тәкъдим ителгән документлар исемлеген билгеләү турында» 506-Т санлы әмерләре, 2010 елның 15 июнендә Татарстан Республикасы Министлар Кабинетының 468нче карары белән расланган, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты положениесе белән, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Содружество» ачык акционерлык җәмгыятенең Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр чите тимер юл транспортында пассажирларны йөрткән өчен икътисади нигезләнгән тарифны бер чакрымлы зона өчен 25,14 сум күләмендә билгеләргә

2. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр чите тимер юл транспортында «Содружество» ААҖ пассажирлар йөрткән өчен чикләнгән тарифлар билгеләү

турында» 2015 елның 16 декабрендәге 7-5/т санлы карарының 1нче пукты үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов